Централизованная религиозная организация
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

Централизованная мусульманская
религиозная организация
Совет муфтиев России

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ,**
**РОССИЯ МӨФТИЛӘР ШУРАСЫ РӘИСЕ**

## МӨФТИ ШӘЕХ
## РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ

## ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА — КОРБАН ГАЕТЕ
## МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һиҗри белән 1442 елның
10нчы зөлхиҗҗә көне
20 июль 2021 ел

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

**БИСМИЛЛӘӘҺИР-**
**РАХМӘӘНИР-РАХИИИМ!**

**Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән!**

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

Бүгенге бөек көндә сезне ихластан сәламләргә рөхсәт итегез:

Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгаләдән иминлек,

Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

КАДЕРЛЕ ДИН КАРДӘШЛӘРЕМ!

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән һәм үз исемемнән Мәккәгә хаҗ төгәлләнгәнлекне белдерүче бөек мөселман бәйрәме Гыйд әл-Әдха (Корбан гаете) белән тәбрикләргә рөхсәт итегез.

Әлеге бәйрәмнең тарихы һәм бу көннәрдә хаҗилар үти торган йолалар безне Ибраһим галәйһиссәлам вә аның улы Исмәгыйл галәйһиссәлам тарихына тоташтыра. Ибраһим галәйһиссәлам тәүһид, ягъни Аллаһның табынуга лаек булган бердәнбер зат икәнен халыкка җиткерүче, бераллалыкны кайтаручы пәйгамбәр булды. Улы Исмәгыйл галәйһиссәлам белән алар Кәгъбәтуллаһны торгыздылар.

Зөлхиҗҗә аеның изге көннәрендә Ибраһим пәйгамбәргә ияреп, Галәмнәрнең хуҗасыннан иманыбызны ныгытуын, йөрәкләребезне пакълавын, туры юлга күндерүен сорап дога кылабыз.

Аллаһы Тәгалә бүгенге бәйрәм көнен бөек гыйбадәт — корбан чалу йоласы белән билгеләгән. Бу йоланы үтәп, Раббысына күндәмлеген һәм Аны яратуын белгертеп, фида кылуның иң югары дәрәҗәсен күрсәткән Ибраһим пәйгамбәр үрнәгенә иярәбез. Игелекле гамәлләребез, шул исәптән чалынган һәм мохтаҗларга өләшенгән корбанлыкларыбыз, ихлас инануыбыз һәм тәкъвалыгыбыз күрсәткече булсын иде.

Гыйд әл-Әдха бәйрәме гаделлек тантанасына олуг өлеш кертә һәм җәмгыятьтә туганлык, үзара ярдәм һәм бердәмлек хисләрен уята.

Мөхәммәт ﷺ үзенең хушлашу вәгазендә: “Бер мөселман башка бер мөселманга туган һәм бар мөселманнар үзара кардәшләр! Бүгенге сөйләвем хәзерге заманга гына кагылмый, бу билгеләнеш һәр чор өчен”, – дигән.

وَلِكُلِّ أُمَّةٍ جَعَلْنَا مَنسَكًا لِّيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَىٰ مَا رَزَقَهُم مِّن
بَهِيمَةِ الْأَنْعَامِ ۗ فَإِلَٰهُكُمْ إِلَٰهٌ وَاحِدٌ فَلَهُ أَسْلِمُوا ۗ وَبَشِّرِ
الْمُخْبِتِينَ. الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللَّهُ وَجِلَتْ

قُلُوبُهُمْ وَالصَّابِرِينَ عَلَىٰ مَا أَصَابَهُمْ
وَالْمُقِيمِي الصَّلَاةِ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ

**“Барча мөэмин җәмәгате өчен корбан чалырга урын кылдык, Без аларга биргән хайваннарны корбан итеп чалганда Аллаһ исемен зикер итсеннәр өчен. Сезнең Раббыгыз бер Аллаһ бит, Аңа буйсыныгыз! Аңа итәгать итүчеләрне шатландыр. Аллаһ зикер ителсә, аларның йөрәкләре тетрәр һәм ирешкән бәла-казага сабыр итәрләр, намазларын вакытында үтәрләр, Без биргән малдан Аллаһ күрсәткән урыннарга сәдака бирерләр.”**
(22: 34–35)

Бу көнне олылау зур ватаныбызның бар халкына рухи тупланыш һәм берлек буларак хезмәт итәр дип чын күңелдән өметләнәм.

“Корбан” сүзе гарәпчәдән “якынаю”, “якын булу” дигәнне аңлата. Дини билгеләмә буларак, бу Аллаһы Тәгаләгә якынаю һәм гыйбадәт кылу нияте белән билгеле бер вакытта хайванны корбан итеп чалуны аңлата. Корбан чалу Исламда мал-мөлкәт белән кылына торган гыйбадәт төрләренең берсе. Ул Аллаһы Тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен шөкрана белгертү. Әлеге йоланы үтәп, без Аллаһка күндәмлегебезне күрсәтәбез.

Галәмнәрне бар кылучыга якынайтачак корбан чалу гыйбадәтен үтәргә теләүчеләргә Аллаһы Тәгаләдән теләктәшлек күрсәтүен сорыйм.

## КАДЕРЛЕ ДИН КАРДӘШЛӘРЕМ!

Быел мөселманнарның күпчелеге хаҗ гамәлләрен башкарырга Мәккәгә бару мөмкинлегеннән мәхрүм. Күпчелегебез вәҗиб булган бәйрәм намазын Җәмигъ мәчетебездә үтәү мөмкинлегеннән мәхрүм. Бу югалтуларны һәрберебез хикмәт һәм буйсынучанлык белән кабул итсен иде.

Динебез кануннары буенча, һәр балигъ, иректә, сәламәт мөселман, физик һәм матди яктан мөмкинлеге булса, гомерендә бер мәртәбә хаҗ йолаларын үтәр өчен Мәккәгә барырга бурычлы. Бер шарт белән: үзе хаҗ кылу дәвамында гаиләсе яки аның карамагындагы якыннары мохтаҗлык кичермичә яшәрлек итеп, аларны тәэмин итеп киткән очракта. Бу мөселманнарга йөкләнгән, хәтта хаҗ кылу таләбе дә үзгәртә алмый торган, якыннарны кайгыртуның гаҗәеп зур җаваплылыгын белгертә.

Галимнәр өммәтебезнең яшәү шартларына һәм ихтыяҗларына үтә дә игътибарлы булган, мәхәллә өчен файдалы булыр өчен дини омтылышларында максатларны һәрвакыт дөрес куйган. Коронавирус пандемиясе аркасында җир йөзендәге күпчелек сыман ук, илебезнең мөселманнары да быел хаҗ кылу мөмкинлегеннән мәхрүм. Хаҗ өчен дип тупланган мөмкинчелекләребезне, хаҗ кылу өчен капкалар бикле дәвердә, өммәтебез файдасына юнәлтергә чакырам. Моның өчен Аллаһ иң хәерлесе белән кайтарачак, иншәАллаһ.

## КАДЕРЛЕ ДИН КАРДӘШЛӘРЕМ!

Әлхәмдүлиллә, бүгенге көнебездә күпчелегебез җәмигъ мәчетләрдә җомга намазларын уку мөмкинчелегенә ия. Бер хәдисендә Аллаһның илчесе Мөхәммәдﷺ җомга намазын “хаҗҗ әлмәсәкин”, ягъни мескеннәрнең

хаҗы дип атаган. Бу шуны аңлата: хаҗ кылуда тарлык, мөмкинлек булмауны кичерүче кешеләр балигъ мөселман ир-аты өчен фарыз кылынган җомга намазын үтәү аша юана һәм Аллаһның рәхмәтенә өмет итә.

Шуңа да күрә, җомга намазларында булыгыз һәм имамнарның вәгазьләрен игътибар белән тыңлагыз. Әлеге гамәлләрнең әҗере Кыямәт көнендә, һичшиксез, үлчәүнең игелекле гамәлләр тәлинкәсендә булачак.

Аллаһтан мөселман өммәтенә тәкъваларны дәрәҗәләргә, ә гөнаһлыларга төзәлергә ярдәм итәчәк зирәк акыл бирүен сорыйм. Аллаһы Тәгаләдән яхшылыкка омтылырга һәм начарлыктан тыелырга ярдәм итүен сорыйм. Чөнки шушы изге максатны тормышка ашыру өммәтебезнең яшәү мәгънәсе бит:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ

**«Сез халык арасына чыгарылган иң хәерле өммәт булдыгыз. Яхшылыкка чакырасыз, яманлыктан тыясыз, Аллаһка иман китерәсез»** (3: 110).

Аллаһы Тәгаләдән барыбызга да ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, бәрәкәт, игелекле эшләрдә уңышлар, ә Ватаныбызга тынычлык, тотрыклылык һәм үсеш, бар сынауларны, шул исәптән куркыныч авыру сынавын узарга ярдәмен сорап ялварам.

Гыйбадәтләребез, корбаннарыбыз һәм бар игелекле гамәлләребез кабул булсын! Гыйд әл-Әдха бәйрәме бәрәкәтендә Раббысына сыенган вә итәгать иткән һәр җан сөенсен, йортларыбыз иман нуры белән нурлансын!

***Корбан гаете мөбарәк булсын!***

**Мөфти шәех Равил Гайнетдин,**
Россия Федерациясе мөселманнары
Диния нәзарәте рәисе,
Россия мөфтиләр шурасы рәисе